# Х.Туфан әсәрләрендә антропонимнар кулланылышы

**Әхмәдгалиева Г.Г.**

Халыкны милләт итеп берләштерә торган могҗиза – аның теле. Милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге туган телнең яшәешенә барып тоташа. Ә телнең яшәеше ана телендә сөйләшү, уку һәм язу, өйдә дә, эштә дә шул телдә аралашу, телеңә булган хөрмәткә бәйләнгән. Туган тел – халыкның меңләгән гасырлар дәвамында дөньяда азатлык һәм бәхет өчен көрәштәге ачыш-табышларын, тәҗрибәсен теркәп килә торган хәзинәсе, хәтере, таянычы, рухы һәм моңы да. [Кәримуллин 1991:44].

Телнең тормыштагы көче – аның сүз байлыгында. Сүз байлыгы милләтебез мәдәниятенең, дөньяны танып-белүнең, рухи хәләтенең көзгесе дә. Телнең сүз байлыгына ул милләт кешеләренең исем-фамилияләре, географик төшенчәләр, торак-пункт атамалары да керә. Ономастика фәне табигать һәм иҗтимагый фәннәр белән тыгыз бәйләнештә тора. География фәне белән аның бәйләнеше табигый. Һәр географик объект үзенең формасы, төсе, төрле сыйфатлары булу нәтиҗәсендә, теге яки бу исемгә ия була. Тарих, археология , этнография фәннәре дә ономастика белән һәрьяклап бәйләнгән.

Ономастиканың киң колачлаган өлкәсе − әдәбият, ягъни әдәби әсәрләр. Әдипләребез үз әсәрләрендә төрле ономастик атамаларга мөрәҗәгать итәләр: кеше исемнәре һәм фамилияләре; шәһәр, авыл атамалары; елга-күлләр исемнәре һ.б. язучыларның үз әсәрләрендә ялгызлык исемнәрен һәрдаим атаулары, кулланулары, аларның әсәрләренә тагын да тирәнрәк мәгънә бирә, укучылар өчен кызыклы итә. Һәм бу һәр язучының иҗатында чагылыш тапмыйча калмыйдыр.

Хәзерге шигъри эзләнүләрнең юнәлешен, мәйданын, сурәтле фикер үсешен Хәсән Туфан иҗаты йогынтысыннан башка күзаллавы кыен. Әдипнең акыллы, моңсу, тирән һәм нәфис лирикасы, аларга хас булганча, башыннан ахырынача кешегә мәхәббәт белән сугарылган, шәхес бәхете өчен көрәш белән рухланган.

Туфан татар поэзиясен яңа иҗтимагый атмосфера, үзенчәлекле эстетик тәҗрибә белән баета. Аның лирикасына чорның фәлсәфи һәм әхлакый эчтәлеген тоя белү, аның рухи матурлыгын дәртләнеп җырлау, вакыйганы хис тирәнлеге белән үрелдереп сурәтләү, тормышчан лиризм һәм шигъри нәфислек хас.

Күпчелек әдипләребез кебек Х.Туфан да үзенең әсәрләрен язган вакытта ялгызлык исемнәрен читтә калдырмый, ягъни ономастик атамаларны шигырьләрендә киң куллана.

Ономастиканың антропонимика, топонимика, оронимика, гидронимика, микротопонимика, этнонимика, зоонимика, космонимика, поэтик ономастика тармаклары һәрберсе азмы-күпме дәрәҗәдә Х.Туфан шигырьләрендә чагылыш табалар. Шагыйрьнең әсәрләрендә иң киң кулланылышка ия булган тармагы – антропонимика.

Татар теленең антропонимик системасында иң борынгы атау-эндәшү функцияләре булып исем һәм кушамат санала. Фамилия белән отчество исә боларга караганда соңрак формалаша. Традицияләр, шул исәптән кеше исемнәре белән мөнәсәбәтле милли традицияләр дигәндә, гадәттә, кешеләрнең гадәтләре һәм йолалары, җәмгыятьнең рухи тормышындагы төрле идея һәм иҗат юнәлешләре күз алдында тотыла. Тарихи урнаша торган күренешләр буларак, традицияләр социаль тәҗрибәнең, үткәндәге иҗтимагый практиканың мөһим элементларын үз эчләренә алалар һәм бу мәгънәдә алар еш кына социаль тәҗрибә төшенчәсе белән бер үк мәгънәдә кулланыла. Бәлки шуңадыр да Х.Туфан үз шигырьләрендә борынгы исемнәребезгә еш мөрәҗәгать итә.

*Шундый йөрәк*
*Алдан әйтеп куя*
*Йә Вәлигә, йә бер* ***Хәлилгә:***
*«Арыдым, кешем... кинәт туктап куйсам,*
*Гафу ит син мине, бәхиллә,*
*Бәхиллә...»*

(«И тормыш...»)

Рус һәм Европа телләреннән кергән исемнәр дә (*Альберт, Лена, Ренат, Светлана* һ.б.) Х.Туфан шигырьләрендә гаять зур урынны алып торалар. Һәм аның шигырьләренең поэтик яңгырашын тагы да арттыра төшәләр.

***Ленин**...*
*Кайда соң ул –*
*Безнең киң күңел?..*
*Әллә ничек авыр, моңсу*
*Ансыз ил көне...*
(«Мә, партия, мине»)

*Гудоклар да инде*
*Һәр таң-иртән*
*Шундый иркә, җылы чакыра.*
*Аларда да миңа*
***Бетховенның***
*Аккордлары гүя чагыла.*
(«Мәхәббәт ул шулай итә икән...»)

Алгадагы шигъри юлларда әдип Кытай һәм Әзәрбәйҗан илләрендәге күренекле кешеләрнең исемнәрен кертеп җибәрә.

*Телеграмм чыбыгы котырган:*
*– **«Сун Ят-сен!»***
*– **«Нәриман!»***
*Күкрәүләр тудырды котыптан котыпны.*
(«Сынган кошлар»)

Татар телендә, башлыча, төрки кеше исемнәренең борынгы төрки һәм болгар чорыннан ук килә торган ике иҗекле традицион җыйнак калыпта кулланылышы йогынтысында, хәзерге антропонимиконыбызда да гарәп, фарсы, рус теленнән алынган җисемнәрнең күбесенчә ике иҗекле җыйнак төзелешкә, җиңел әйтелешкә, матур яңгырашка һәм дөньяви мәгънәгә ия булганнары популяр. Мәсәлән, *Фәрит – Фәридә, Рәшит – Рәшидә, Мансур, Сания, Шамил, Камил, Кадрия, Наил – Наилә, Равил – Равилә, Әлфия, Зөлфия, Рәис, Рәисә* һ.б. Әлеге исемнәрне Х.Туфан шигырьләрендә дә күпләп очратырга мөмкин:

*Хатыны малай тудыргач,*
*Үзен бик егет санап*
*Боргалап кара мыекны*
*Мактанып йөрде **Самат**.*
(«Кыз бала»)

Бу төркем исемнәр арасыннан Луиза исеме аеруча игътибарга лаек, чөнки бу исем  Х.Туфанның тормыш иптәше – Луиза Салигаскәрованың исеме.  Автор шигырьләрендә һәрдаим аңа мөрәҗәгать итә. Туфан аңа Луиза дип кенә түгел, ә яратып «Лу», яки «Лулу» дип тә эндәшә. Гүя шул рәвешле ул үзенең ярату хисләренең зурлыгын, бөеклеген күрсәтергә тели. Әлеге исемнәр аркылы без Х.Туфанның хәләл җефетен ни дәрәҗәдә яратуын һәм кадерләвен күрәбез.

*Хәтер генә бераз аралый бит*
*Сагышлардан безне әлегә*
*«Сагынасыңдыр син дә* ***Луны****?» – дисең,*
*Сагынмаган кайда, Әминә!..*
(«Кагылмагыз, карлар, истәлеккә»)
*Алып киттең мине үзеңә син*
*Ракташ, Кутуй гаиләсеннән*
*Завод семьясына. Мең кат риза,*
*Мең кат риза,* ***Лулу****, мин синнән.*
(«Саф җаннарда гына була торган...»)

Шагыйрьнең кайбер шигырьләрендә күренекле әдипләребезнең исемнәрен очратырга мөмкин.

***Тукайлар, Бабичлар, Такташлар, Мусалар,***
***Кутуйлар, Бурнашлар, Камаллар*** *йортына*
*Әрсезләр, гамьсезләр, дөм-сукыр тычканнар,*
*Бөҗәкләр ябырыла, абына-сөртенә,*
***Галимҗан*** *абыйлар,* ***Әмирхан*** *өенә,*
*Намуссыз, битсезләр өелә.*
(«Тукайлар, Бабичлар, Такташлар, Мусалар...»)
***Такташ*** *китте,* ***Җәлил, Кәрим, Сәйдәш****...*
*Аз идеме? Ә бүген –* ***Кави****.*
*Яраларын ямап өлгермәгән*
*Йөрәкләр яңадан кайный.*
(«Шагыйрь туганыма»)

Югарыдагы мисалларда бер строфада берьюлы күпләгән язучы-шагыйрьләрнең исемнәре урын алган. Х.Туфан татар әдәбиятындагы күренекле әдипләребезнең исемнәренә мөрәҗәгать итә, аларны энҗе бөртекләре кебек, бер-бер артлы тезеп безгә җиткерә. Шунысын да искәртергә кирәк: әлеге исемнәр кебек үк Х.Туфан башка халык язучыларының да исемнәрен шигырьләрендә куллана.

*...Үкереп янган җырлар, поэмалар*
*Азмы роман, повесть, кыйссалар,*
*Һәм үзләре көчкә исән калган*
***Остап Вишня, Ручьев, Метталар****.*

*Һәм исеме дә хәтта җәзаланган,*
*Юк ителгән әдип, шагыйрьләр:*
***Галимҗаннар, Чаренц, Тицианнар***
***Карниловлар, Юлтый, Сәкеннәр***
*Тергезелде.*

(«Хатлар яза идек»)

Кеше исемнәре, отчестволары һәм фамилияләре белән беррәттән, шәхесне атау өчен **кушаматлар** киң кулланыла. Кушамат аралашуны, аңлашуны җиңеләйтү, кем турында сүз алып баруны төгәл, ачык итү өчен ярдәм итә торган антропонимик чара булып тора. Х.Туфан татар исемнәрен бозып сөйләшүләре, яки аларны бөтенләй рус исемнәре белән алыштырып сөйләшүләренә борчыла, бөтен йөрәге белән моңа каршы чыга. Бу исемнәргә шагыйрь кушаматлар мәгънәсендә кулланылган «атамалар» итеп карый. Мондый исемнәрнең бер дә матур күренеш булмавын һәм телебезне пычратуын янә бер кат раслый. Мәсәлән:

*Исемнәре:* ***Марго, Зигфрид, Нэрик***
*Ягъни:* ***Мәрьям, Фәрит, Нургали***
*Очрашканда безнең арабызда*
*Тел хакында бәхәс булгалый.*

(«Алмаз»)

Мисаллардан күренгәнчә, Х.Туфан кеше исемнәрен төрле максатлардан чыгып: кемне дә булса кисәтү өчен, киңәш бирер өчен, бер кешене икенче берәү белән чагыштырыр яки шаяртыр өчен файдалана. Аның иҗатындагы антропонимнарны тикшергәннән соң, Х.Туфан башкалардан оригиналь стиле, сүрәтләү чаралары үзенчәлекле булуына, тормышта күз иңли алмаслык зур нәрсәләрнең бер караудa күңелгә сыйдыра алырлык, җыйнак сурәтләрен иҗат итә алуына тагын бер кат инандык.

## Әдәбият

1. Саттаров Г.Ф. Татар антропонимкасы / Г.Ф. Саттаров. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1990. – 278 б.

2. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле / Ф.С. Сафиуллина, М.З. Закиев. − Казан: Мәгариф, 2002. − 403 б.

3. Туфан Х. Сайланма әсәрләр / Х.Туфан. − Казан: ТаРИХ, 2004. − 431 б.